| | |
|---|---|
| **СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «КУАКБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КУАКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| **2018 елның 31 июле** | **№ 19** |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 28 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм тәртипкә карата бердәм таләпләрне билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 28 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 бүлекнең 7 пунктындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-территорияне төзекләндерү - муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру, гражданнарның яшәү шартларын яхшырту, муниципаль берәмлек территорияләренең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итү һәм яхшырту, мондый территорияләрдә урнашкан торак пунктларның территорияләрен, шул исәптән гомуми кулланылыштагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен,

биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тоту буенча эшчәнлек;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авыл җирлеге буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова